КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

30.10.2025 № 1

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2025 елның 30 октябрендә узган гражданнар җыенында «2026 нчы елда Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенә керүче Явлаштау торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең Явлаштау торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Явлаштау торак пунктында агачларны кисү, вак куакларны чистарту).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 275 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 142 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 142 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2.«2026 нчы елда Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенә керүче Явлаштау торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең Явлаштау торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Явлаштау торак пунктында агачларны кисү, вак куакларны чистарту) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Явлаштау

авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Явлаштау авыл җирлеге башлыгы — Б.А.Нәҗипов